
БАСМА СҮЗ ОСТАСЫ



Татарның зыялы улларыннан берсе Фатыйх Кәрими, милләт өчен күпкырлы хезмәт иткән шәхес. Аның бөтен яшәве — ижаты, хезмәте бер-берсен тулыландырып, гомерлек максатына хезмәт итә. Мәкаләбездә аның публицистик эшчәнлегенә күпмедер күзәтү ясап, бәя бирү максатын куйдык.


Газета чыга башлаган көннәрдә талантлы беллетрист, милләтенә бөтен барлыгы белән бирелгән, халкын агартуда шактый авыр миссияне үз өстенә алган мөхәррир Фатыйх Кәриминең исеме, мөселман дөньясында инде танылып өлгергән була. Сүз 1906 елның 21 февраленнән 1918 елның 26 гыйнварына кадәр Рәмиевләрнең матди ярдәме белән Оренбургта чыккан иҗтимагый-сәяси «Вакыт» газетасы хакында. Газетаның көтеп алынганлыгы турында «Оренбургский край» исемле газетада Ю. Музаферов исеменнән бастырылган мәкалә сөйли: «Бүген, 21 февральдә, Оренбург краенда татар телендә беренче һәм бердәнбер "Вакыт" газетасының беренче саны чыга. Россиянең үзаңы уянган барлык мөселманнары, милләт офыгында кабынган бу таң йолдызы белән, горурлана алалар. Мөселманнарның таләпләрен һәм ихтыяҗларын һәръяклап яктырту өчен "Вакыт" газетасына авыр һәм катлаулы юл үтәргә туры киләчәк. [...] Милләтебезнең үз идеяләрен тормышка ашыруына юнәлтелгән чиктән тыш кыен миссиясен үтүдә мәдәни-прогрессив газетага уңышлар телисе генә кала»[1].

Газета чыгару эшендә каршылыклар да булып тора. Мәсәлән, мәҗбүри рәвештә цензор кулы аша үтү, тентүләр, әзер номерларга арест салу, штраф түләтү, панисламистик пропаганда ясауда гаепләү һ. б. Әмма әлеге күңелсез вакыйгалар гына мөхәррирне халкына хезмәт итүеннән чигендерә алмый.

Укучы фикере газетаны башка, уңай яктан характерлый. Чыга башлап ике-өч ел үтүгә, әлеге газетаның бөтенләй басылмавын күз алдына да китереп булмый. «Вакыт»ның теле дә барлык төрки халыклар укып аңларлык була.

Эчтәлегенә килгәндә, газета төрле сорауларга җавап эзли. Арада мөселман уку йортларына бәйле мәгариф системасына реформа үткәрү, шул нисбәттән Дәүләт Думасы һәм хөкүмәт эшчәнлеге белән дә таныштырып бару; татар алфавитын камилләштерү; хатын-кыз мәсьәләсе; тормыш дәрәҗәсен күтәрү максатыннан җир эшкәртүнең яңа алымнары; сәүдә һәм һөнәрчелекне үстерү; тел һәм әдәбият, халык авыз ижаты; милли театр һәм музыка; Оренбургта милли музей ачу; дәүләт мәктәпләрендә уку, рус телен өйрәнү һ. б. турында материаллар бар. Шул ук вакытта чит илләр һәм Россиядә барган яңалыкларга да урын бирелә. Л. Н. Толстой әсәрләре, М. Ю. Лермонтов поэзиясе, М. В. Ломоносов хезмәтләренең тәрҗемәләре һ. б. кебек барлык прогрессив күренешләр көн үзәгендә тотыла.

Бу нисбәттән Татарстан дәүләт ар-



Гыйльман ахун, Ф. Кәриминең әтисе.
1875 ел.



Гыйльман Кәрими җәмәгате Мәгъсүмә һәм уллары Гариф белән. Уфа, 1893 ел.

хивының Фатыйх Кәрими фондында сакланган материалларны искә алып үтү кирәк. Башка бик күп истәлекле кәгазьләр арасында Л. Толстойның 1901 елның 4 апрелендә Ф. Кәримигә атап язылган хаты да бар. Хат язылган дәвердә, төгәлрәк әйткәндә, 1901 елның 20-22 февраль көннәрендә Синод тарафыннан чыгарылган карар бөтен Россия җәмәгатьчелеген кузгалта. Әлеге күтәрелеш Л. Толстойның чиркәүгә мөнәсәбәте белән бәйле була. Мәшһүр шәхеснең үзе хат язуы да кызыклы. Димәк, Кәрими рус җәмәгатьчелегендә барган вакыйгалардан хәбәрдар булып, бәлки Толстойның үзенә хат язган һәм мәсьәләнең торышы белән кызыксынган булгандыр. Бөек әдип, мөселман кешесенә үзенең дөньяны кабул итүен дустанә мөнәсәбәттә аңлатып язган булырга мөмкин. Әлеге вакыйгадан соң Л. Толстой үзенең рус җәмәгатьчелеге, чиркәү вәкилләреннән бик күп санлы һәм төрле эчтәлектәге хатлар алуы хакында язган[2].

Кәриминең дөнья белән бергә атлавын раслый торган тагын бер факт — аның газета битләрендә укытучыларны берләшеп, уку-укыту мәсьәләләрен хәл итү өчен съезд оештыруга чакыруы. Билгеле булганча, мондый хәрәкәт рус җәмәгатьчелегендә дә барган. XIX-XX гасырлар чигендә Россиядә укытучылар, табибләр, рәссамнар һ. б. һөнәр ияләре үзләренең съездлар оештырып, көнүзәк проблемаларны күтәреп чыга.

Россия күләмендә XX гасыр башында чыгарылган газеталар арасында «Вакыт» үзенең җитдилеге һәм төплелеге белән аерылып тора. Моны тәэмин итүчеләр — мөхәррир һәм редакция хезмәткәрләреннән тыш, язышып торучы авторлар — Һ. Атласи, З. Бәшири, М. Бигиев, З. Вәлиди, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, С. Сүнчәләй, Р. Фәхретдинов, Б. Шәрәф һ. б.

Эчтәлегеннән күренгәнчә, «Вакыт» заманының алдынгы фикерле буржуаз катлавы һәм интеллигенциясе өчен менә дигән газета булып торган.

Басманың ни дәрәҗәдә заман таләпләренә җавап бирерлек икәнлеген аңлау өчен матбугат битләрендә, шул елларда ук, дөнья күргән бәяләмәләр белән танышу да җитә. Болар — танылган венгр тюркологы Армени Вамберинның (1832-1913) 1906 елда «Times» редакторына (шул елның 28 март санында басылган)[3] һәм 1913 елның апрелендә

Оренбургка язылган хатлары[4]: әдәбият галиме Г. Сәгъди[5] һәм үзбәк халык шагыйре Хәмзә Ниязи (1889-1929) истәлекләре[6]; татар журналисты Сәхи Рәхмәти язмалары. 1923 елда «Яңа Шәрык» журналы да «Вакыт»ның Урта Азия интеллигенциясенә булган йогынтысы хакында яза: «Бохара ханлыгында яшьләр һәм либерал сәүдәгәрләргә беренче булып оешкан төстә инкыйлаби фикер алып килүче татар милли вакытлы матбугаты булды. Бакчасарайда басылган "Тәрҗеман", Казанда (Оренбург урынына Казан дип ялгыш язылган) басылган "Вакыт", Тифлиста чыга торган иҗтимагый-сатирик журнал "Хуҗа Насретдин" һ. б. шундыйлардан. "Вакыт"ны кыю рәвештә революцион басма дип әйтеп булмаса да, аның Урта Азиядә популяр булуы шиксез»[7].

Ф. Кәриминең тормышы һәм эшчәнлеге тулаем караганда, аның беренче нәүбәттә публицист, мөхәррир икәнлеге күрәбез. Мөгаен, ул үзе дә тормышын «Вакыт» редакциясеннән башка күз алдына китермәгәндер. Газетаның һәр санында аның мәкаләсе беренче юлларда басыла. Моннан тыш ул аналитик характердагы мәкаләләр дә язып килә.



Фатыйх Кәрими. Истанбул, 1896 ел.



Гариф Кәрими.

Бары шушы эшчәнлегеннән тыш вакытта гына ул китап-дәреслекләр төзеп бастыру һәм рус, чит телләрдән башка авторларның хезмәтләрен тәрҗемә итү белән мәшгуль булган, дип уйларга урын кала.

Каршылыклар белән булса да, уңышлы гына барган тормышка инкыйлаби үзгәрешләр үтеп керә башлый. Актив яшәүче Ф. Кәриминең әдәби-публицистик эшчәнлегендә фикри үсеш тә эзсез калмагандыр, 1917 елда газетаның наширләре белән арада килешмәүчәнлек килеп чыга, һәм ул редакциядән китә. Мөхәррирлек вазифасы Ярулла Вәли кулына күчә. Билгеле булганча, Ф. Кәрими шул ук елда «Яңа вакыт» газетасын чыгара башлый. Әлеге басманың фикри юнәлеше турында Ф. Кәрими үзе болай дип билгели: «"Яңа вакыт" вә аның мөхәррире большевик түгел, хәтта бер партиягә мөнасиб (ярашлы) социалист та түгел, ул хөр фикерле, тәрәкъкый вә тәмәдден (мәдәниятле булу) тарафдары бер милләтчедер. Аның идарәсендә булган "Яңа вакыт" та партиягә мөнасиб булмаган хөр вә тәмамилә мөстәкыйль тәрәкъкыйпәрвәр бер гәзиттер. "Яңа вакыт" тәмам хөррият фикерилә ватан вә



Фатыйх Кәрими гаиләсе белән. Уфа, 1911 ел.

милләт мәнфәгатен күзәтергә тырыша. Шул хакта үз белгәнен, үзе хак дип игътикад иткәнен яза…». (1991 елдан Оренбург шәһәрендә, әлеге «Яңа вакыт»ның дәвамы кебек, шул исемдә кабат татарча газета нәшер ителә башлады)[8].

Ләкин «Яңа вакыт» озын гомерле булмый. Совет хакимияте, буржуаз газеталар дип, 1918 елның 26 гыйнварында «Вакыт»ны һәм 1918 елның 22 мартында «Яңа вакыт»ны яба, басмаханәләре дәүләт кулына алына. «Вакыт» ябылу хакында барлык милли газеталарда Ярулла Вәлинең түбәндәге белдерүе басылып чыга: «“Вакыт” мөштәриләренә (яздырып алучыларына). 1918 ел 26 гыйнвар иртә сәгать унда Оренбург Мөселман военный революцион комитет (хәрби комитет) тарафыннан унике ел милләт хезмәтендә дәвам итеп килгән “Вакыт” гәзитәсенең матбагасы, кәгазе конфисковать (мөсадәрә) ителде вә гәзитә туктатылды, вә банкыдагы акчасы, ярты миллионнан артык торган бу мөәссә (учреждение, матбага күздә тотыла) мәзкүр (югарыда әйтелгән) комитетка күчкәнгә, “Вакыт” вә “Шура” мөштәриләре каршында ул мәсьүлдер. Бу хәлнең вөҗүдкә (барлыкка) килүенә итәк астыннан һәм ачыктан-ачык хезмәт иткән кешеләргә татар тарихы, әлбәттә, тиешле мөкяфәтне бирер (бүләкне; бу урында “тиешле бәһане бирер” мәгънәсендә киная белән әйтелгән). Наширләреннән вәкил — Ярулла Вәли»[9].

«Вакыт»ның, редакциянең беренче көненнән башлап, 12 ел дәвамындагы тормышына күзәтү ясаганнан соң, бүгенге фән-техника үсеше күзлегеннән карап редакциянең тиз арада «аякка басып», хөрмәт казануын, бигрәк тә рухи яктан уңышлы басма булуын күрәбез. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башы аралыгында дөнья күргән дистәләгән татар газеталары арасында, лидер ролен үтәгән ике басманың берсе ул «Вакыт». Ике очракта да уңышның күп өлеше эчтәлек, дизайн, материалның уңышлы бирелүе белән турыдан-туры мөхәррирenә бәйле.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Материалы научно-практической конференции [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.lira.jren.ru.
2. Татарстан Милли архивы, 1370 ф., 1 тасв., 26 сакл. бер., 28 кгз.
3. Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык / Төз.-авт. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. – Казан, 2000. – Б. 176.
4. Ахунов А. Запечатленное слово Фатиха Карими [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://www.tatmir.ru.
5. Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик… – Б. 180.
6. Ахунов А. Указ. соч.
7. Там же.
8. Рәми И. Г., Даутов Р. Н. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан, 2001. – Б. 322.
9. Шунда ук. – Б. 61.

Фотолар Казан милли мәдәният үзәге каршындагы Милли мәдәният музееннан алынды.

Миләүшә Сибгатуллина

РЕЗЮМЕ

Статья Миляуши Сибгатуллиной посвящена публицистической деятельности Фатиха Карими, главного редактора газеты «Вакыт», выходившей в Оренбурге в 1906-1918 гг.